| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03 октября 2025г. № 11

п.г.т. Алексеевское

**Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 2008 елның 20 июнендәге №48 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогының көнбатыш һәм көнчыгыш районнарын үстерүнең генераль планы һәм планлаштыру проекты турында» карарының үз көчен югалтуын тану хакында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гамәлдәге генераль планга һәм җирдән файдалану һәм территориядә төзелеш алып бару кагыйдәләренә туры килмәүгә бәйле рәвештә,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар кылды:**

1. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 2008 елның 20 июнендәге №48 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогының көнбатыш һәм көнчыгыш районнарын үстерүнең генераль планы һәм планлаштыру проекты турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**